СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

15 ноябрь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 129 (8141) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ИРТӘГӘ - АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ ЭШКӘРТҮ ТАРМАКЛАРЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КӨНЕ

## УРТАК БӘЙРӘМЕБЕЗ БЕЛӘН!

***Кадерле авыл эшчәннәре, хөрмәтле эшкәртүчеләр!***

*Иртәгә - авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең, агропромышленность комплексына кагылышы булган барлык тармак эшчәннәренең дә һөнәри бәйрәме. Әмма без аны барчабызның да уртак бәйрәме дип саныйбыз, чөнки нәкъ менә Сезнең фидакарь хезмәтегезнең җимешләре безнең барыбыз өчен дә яшәү чыганагы булып тора. Өстәлләребездә һәр көнне Сезнең кул җылыгыздан да күпереп пешкән икмәк булганга, табыннарыбыз башка нигъмәтләрдән тулып торганга безнең дә күңелебез көр, эшкә дәртебез зур.*

*Районыбызның агропромышленность комплексы хезмәткәрләре быелгы һөнәри бәйрәмнәренә аеруча зур хезмәт казанышлары белән килделәр. Уртак тырышлык нәтиҗәсе буларак районыбыз кырларыннан гомер күрелмәгәнчә югары иген уңышы җыеп алынды һәм район дәүләткә ашлык сату буенча килешү йөкләмәсен республикада иң беренче булып үтәп, Татарстан амбарларына йөкләмәдән тыш та шактый күләмдә ашлык салды. Кабул ителгән 90 мең тоннага якын бөртекле ашлыкның 56 мең тоннадан күбрәге яхшы сыйфатлы ашамлык бодае булды. Шундый югары уңыш үстерү һәм аны югалтуларсыз җыеп алу авыл халкына зур булышлык күрсәткән «Агрохимсервис» һәм «Сельхозтехника» акционерлык җәмгыятьләре, МТС, автотранспорт һәм башка төр техника, эшче куллар белән булышлык иткән шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары коллективларының уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә мөмкин булды.*

*Терлекчелек өлкәсендә күрелгән киң колачлы оештыру - техник чараларның нәтиҗәсе буларак, район сөт җитештерү һәм хәзерләү буенча алга зур сикереш ясап, республикада иң алдынгы урыннарның берсенә чыгуга иреште, дәүләткә сөт һәм ит сатуның еллык килешү йөкләмәләре вакытыннан бик күпкә алдан арттырып үтәлде, сыер саву уңганнарыбыз быелгы бәйрәмне, элекке даннарын кире кайтарып, ун айда бер сыердан уртача 3 мең килограммнан күбрәк сөт савып каршылыйлар. Продукция муллыгы һәм аны эшкәртүчеләрнең зур тырышлыгы халыкны сөт һәм ит продуктлары белән тоткарлыксыз тәэмин итүне сизелерлек яхшыртырга мөмкинлек бирде. Ә дуңгыз ите җитештерү һәм эшкәртүнең тәмамланган циклын кертүгә юнәлдерелгән чаралар халыкның яхшы сыйфатлы казылык продукциясенә ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерүгә ирешүне күздә тота.*

*Бүген календарьда бәйрәм булса да, авыл кешесенең мәшәкатьле хезмәте бер генә көнгә дә тукталып тормый. Гаять катлаулы табигать шартларында да татлы тамыр казуны төгәлләп чыга алган игенчеләребез алдында шикәр чөгендерен дәүләткә озатып бетерү кебек гаять җаваплы бурыч тора һәм алар бу авыр чакта да партнерларының ышанычлы ярдәмен тоялар. Терлекчелектә бик җаваплы - кышлату чоры башланды. Эшкәртүчеләр, авылга техника , ашлама белән һәм башкача булышлык итәргә чакырылганнар алдында да җаваплы эшләр күп. Халык депутатларының район Советы президиумы, район хакимияте исеменнән барчагызга да илгә кирәкле хезмәтегездә яңа казанышлар, зур түземлелек , ныклы сәламәтлек, гаилә тынычлыгы һәм бәхет телим.*

***Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН,***
*халык депутатларының район Советы рәисе, хакимият башлыгы.*

## Бәйрәмгә - котлаулар

**Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көне уңаеннан район җитәкчелеге исеменә күпсанлы котлау телеграммалары алынды.**

**Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры В.П.Васильев кул куйган телеграммада мондый юллар бар:**

***«Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович! Сезне һәм районның барлык хезмәтчәннәрен бәйрәм белән котлыйбыз. Фидакарь хезмәтегезгә, үткәргән зур оештыру эшегез, авылның социаль - икътисадый үсеше турында армый - талмый кайгыртуыгыз өчен ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.***

***Һөнәри бәйрәм уңаеннан Сезгә һәм районның аграр секторындагы барлык хезмәтчәннәргә, район оешмалары коллективларына ныклы сәламәтлек, бәхет, гаилә иминлеге, яңадан - яңа уңышлар телибез».***

***

**Бәйрәм уңаеннан шундый ук изге теләкләр белән котлау телеграммалары Казан шәһәре хакимияте башлыгы К.Ш.Исхаковтан, Арча һәм Яңа Чишмә районнары хакимиятләре башлыклары В.В. Минһаҗевтан һәм Н.М.Владимировтан, Азнакай һәм Чүпрәле районнарының авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәләре башлыклары Гыйльманов һәм Гафуров, «Промтранссервис» АҖ генераль директоры Давыдов, «Казан ит комбинаты»АҖ генераль директоры Хөсәенов иптәшләрдән дә алынды.**

**Бәйрәм котлаулары килү дәвам итә.**

Яңалыклар

## Кулларыннан гөл тама

Тимер юл ОРСы коллективы иртәгә үтәчәк бәйрәмне күпмедер дәрәҗәдә үз бәйрәме буларак та билгеләп үтә. Быел да коллектив бу көнгә югары хезмәт җимешләре, зур хәзерлек белән килде. Коллективның үзенә җиткерелгән барлык заданиеләрне дә уңышлы үтәве дә шул турында сөйли. Гомуми уңышка 4 нче ашханә мөдире Рушания Нәфыйгина, пешекчеләр Лариса Максимова белән Раиса Иванова, аларның ярдәмчеләре Лилия Ибраһимова һәм Фәридә Зәйнуллина, кондитер Ирина Круглина аеруча зур өлеш керттеләр.

Икмәк пешерүчеләребез турында да мактау сүзләрен күпләп әйтергә мөмкин булыр иде. Рәисә Ильмухина җитәкчелегендәге пекарняда дус, тату бердәм коллектив оешты. Гөлфия Гыйләлова, Гөлсинә Минхәерова, Зөлфия Бикиниева, Мәрьям Бакирова, Любовь Хәлитова кебек уңган кызларыбыз тимер юл пекарнясының данын югары тоту өчен ал - ял белән санашмыйча эшлиләр. Зөбәрҗәт ханым турында аерым әйтәсем килә. Ул пекарняда эшләве белән бергә, берүзе берничә сортлы макарон әйберләре дә җитештерергә өлгерә.

Гомумән, кызларыбызның барысы да булганнар, кулларыннан гөл тама торганнар.

**Н.САФИУЛЛИН,**
**ОРС начальнигы.**

## Өч мең чиген уздык

***Район хуҗалыклары быел ун айда бер сыердан уртача 3001 килограмм сөт савып алдылар. Хуҗалыклар буенча күрсәткечләр мондый:***

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Кондырча» | 5609 | «1 нче Май» | 2874 |
| «Дуслык» | 5509 | «Татарстан» | 2859 |
| Мичурин исем. | 5066 | Сөт - май комбинаты ярд. хуҗ. | 2826 |
| «Агрохимсервис» ярд.хуҗ. | 4070 | «40 лет Победы» | 2753 |
| «Рассвет» | 3982 | «Төрнәс» | 2729 |
| «Якты Күл» | 3770 | «Заря» | 2615 |
| Хафизов исем. | 3554 | Нефтебаза ярд. хуҗ. | 2502 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 3528 | «Таң» | 2488 |
| | | РСУ ярд. хуҗ. | 2474 |
| «Родина» | 3209 | «Үрнәк» | 2390 |
| «Киекле» | 3406 | «Игенче» | 2285 |
| «Чирмешән» | 3141 | «Әлмәт» | 2280 |
| М.Җәлил исем. | 3073 | «Алга» | 2168 |
| «Заветы Ильича» | 3047 | МСО ярд. хуҗ. | 2097 |
| Синдряков исем. | 3007 | «Комбайн» | 1803 |
| Кузнецов исем. | 2975 | **Район буенча** | **3001** |

Яңалыклар

## Хатын - кызлар кыюлана

Агымдагы атнада оборона - спорт - техника оешмасы район Советы каршындагы шоферлар хәзерләү курсларында укучы ике төркем автосөючеләр имтихан тотты. Курсларга йөрүче 60 кешенең 56сы имтиханны уңышлы тапшырды. Якын көннәрдә алар кулларына җиңел автомобильләр йөртүгә хокук бирүче яңа үрнәктәге «В» категорияле шофер таныклыгы алачаклар.

Шунысын да әйтергә кирәк, булачак шоферларның 18се - хатын - кызлар. Кыюлана бит хатын - кызларыбыз!



**Салих Хәйретдинов - шофер, Равил Хәмmәтҗанов тракторчы. Бер хезмәт участогында эшләргә еш туры килә аларга. Быел азык хәзерләү чорында икесе дә яшел азык ташыдылар. Урып - җыю эшләре башлангач та еш очрашырга туры килде механизаторларга.**

**Салих «КамАЗ» автомашинасын йөртә. Ерак рейсларга йөрергә, әрҗәсенә җаваплы йөк - ашлык төяп элеваторга юл тотарга, ындыр табагында эшләргә, башка төрле нарядлар үтәргә туры килә аңа. Хәер, автотранспорт өчен эш бетәмени хуҗалыкта. Салих исә йөкләнгән һәр вазифаны җиренә җиткереп башкара.**

**Равил дә «Киекле» КХАсында булдыклы механизаторлардан санала. Җир сөрә, туфрак эшкәртә, йөк күчерә ул. Үз хезмәтенә югары җаваплылык хисе аерып тора аны башкалардан.**

**Рәсемдә: С.Хәйретдинов, Р.Хәмmәтҗанов. Н.АЗИЗОВ фотосы.**

Яңалыклар

## Агачлар тернәкләнеп китсә...

Г.Гыйматдинов исемендәге урамдагы РСУ төзегән яңа йортлар буйлап киң һәм биек итеп салынган тротуардан баруы бик уңай. Берничә елдан, МПП яшелләндерүчеләре утырткан агачлар да тернәкләнеп китсә, тротуар үзенчәлекле ял урынына да әвереләчәк әле дип ышаналар шәһәрлеләр.

Яңалыклар

## Норлаттан Ульяновск еракмы?

Ерак, дияр берәү. Ә менә автобуста җилдерүчеләр бу араны, кем әйтмешли, җырлап үтәләр. Яңа Маршрут - Ульяновск - Норлат автобусы көндезге сәгать бердә Норлат автовокзалыннан пассажирлар утырта да берничә сәгать эчендә Ульяновск шәһәренә илтеп җиткезә. Шулай булгач бу шәһәргә ара ерак дип була мени инде?! Халык моңа бик риза.

# Сезнең хатларыгыз эзеннән

## Утын җылытмады, «көйдерде»

Яңа Әлмәт авылында яшәүче Наилә апа өенә Октябрь урман хуҗалыгының Бутайха урманчылыгы һәм җирле үзидарә вәкилләре ишек кагып, агач тәкъдим иткәч, шатлыгы эченә сыймады. Сөенмәслек тә түгел шул: утынлыкта утыны булса да, запас һичкайчан артык түгел. Өстәвенә, мәшәкате дә аз булачак: үзең урманнан хәзерләтеп кайтарткannan күпкә арзанга да төшәчәк диләр. Урман хуҗалыгы вәкиле үзе санап - исәпләп күрсәтте: 1 метрлы 8 кубик метр агач өчен нибары 378 мең сум түлисе булачак. Иң мөһиме, акчаны кулдан бирәсе дә түгел: процентлап, пенсиясеннән тотып калачаклар.

Килештеләр болар. Вәгъдәләрен үтәүне дә озакка сузмадылар урманчылар: күп тә үтмәде Фәхретдинова йорты капка төбендә зур утын өеме хасил булды: 8 кубик метр урынына хәтта 12не китергәннәр булып чыкты урманчылар. Сөенеченнән, кем әйтмешли, башы күккә тигән хуҗа хатын хәтта алар калдырып киткән документка да күз салырга онытты. Бераздан, аларны алып карыйм әле дип кәгазьләргә тотынса, егылып китә язды. Сигез кубик метр утынга бирелгән номерсыз ордерда утын бәясе 503 мең 600 сум күрсәтелгән. Дөрес, төп бәясе килешенгәнчә икән - 378 мең сум. Әмма шуңа үзара телдә килешүдә сөйләшенмәгән 75.600 сумлык НДС, моннан тыш, автомашина хезмәте өчен 50 мең сум да өстәлгән. Мастер М.Закиров аркылы җибәрелгәнен алты кубометр утынның номерсыз икенче документында да шул ук НДС, автомашина хезмәте белән бергә бәясе 390.200 сум булган. Барысы бергә 893.800 сум килеп чыга.

- Утынның мондый бәягә төшүен белгән булсам, моңа һич ризалашмый идем. «Утын кирәкмиме», дип ишек шакып, утын сатып йөрүчеләр дә күп бит,- дип бик озак көенә Наилә апа. Ярар, киләчәккә сабак булыр дип, тынычлана аннары. Район социаль тәэминат бүлеге исә урман хуҗалыгыннан килгән документ нигезендә быелның июнь аеннан 166ар мең сум акча тотып кала башлый. Болай да аз пенсия алучы кеше өчен бик сизелә бу сумма. Инде түләп бетерәм дип, пенсия көткән көннәрендә сатып алган хәсрәте янә «кабара» - тәэминат бүлеге Н.Фәхретдинова пенсиясеннән 1 миллион 7 мең 200 сум акча тотып калырга ниятләве беленә. Җаваплары бер генә: безнең өчен төп нигез - документ. Шуннан соң Наилә апа редакциягә мөрәҗәгать итте. Әлеге факт уңаеннан беренче булып тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать иттек без. Алар Н.Фәхретдиновага биргән җавапларын расладылар: пенсия фондының район бүлеге аркылы кергән документ бар, һәм, анда әлеге сумма күрсәтелгән.

Җепнең очын исә Октябрь урман хуҗалыгыннан таптык. Баксаң, документта төгәлсезлек Бутаиха урманчылыгында ук җибәрелгән булган: ордерларда сумма бер төрле булып та, реестрга икенчесе язылган. Һәм шул килеш ул бүлеккә дә барып ирешкән.

Билгеле инде, адәм баласы хатадан хали түгел. Әмма шунысы гаҗәп: хисап хезмәткәренең акча түләүче файдасына алданмаганнар, НДСны да төшереп калдырмаганнар бит. Ә аермадагы сумма пенсионер өчен аз нәрсә түгел. Шуңа да монда инде гарьләнерлек урын бар. Ә Наилә апа кебек яхшылык көтеп тә беръюлы ике тапкыр яманлыкка, алдауга юлыккан беркатлы кеше өчен икеләтә гарьлек.

Урман хуҗалыгы соңлап булса да, хаталарын танып, Н.Ф.Фәхретдиновадан документлардагы суммадагы аерма - 113.400 сум акчаны кире кайтарырга булдылар.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Газ булыр, җылылык юк...

Степан Разин урамының 2 «а» йортында яшәүчеләрнең өйләрендә җылылык җитмәүгә интегүләре хакында редакциягә беренче язулары гына түгел. Менә быел яңа җылыту сезоны башлануга анда яшәүче 7 хуҗа имзасы куелган хат килде һәм анда шундый юллар бар: «Сельхозтехникага җылылык өчен айныкын - айга түләп барсак та, кышын өйләрдә батареялардан суык бәрелә. Өстәвенә быел июнь аенда плитәләргә табигый газ үткәрү өчен акча да түләгән идек. Әмма бүгенгә кадәр ул да килгәне юк әле».

Бу хат эзеннән без шул йортта булып, анда яшәүчеләр белән очраштык һәм анда язылганнарның дөреслеккә туры килүен раслыйбыз. Шул ук вакытта ике предприятие «Татагропроммехмонтаж» һәм «Сельхозтехника» АҖләре җитәкчеләре С.В.Филлипов һәм М.Ю.Жемков белән элемтәгә кердек.

С.Филлипов җавабыннан аңлашылганча, фатирларга газ кертү эшләре тулысынча төгәлләнгән. Ләкин хикмәт шунда ки, газлаштыру максатында җәен фатир хуҗалары түләгән акчалар гына аз дип табыла һәм АҖнең Казандагы баш идарәсе тарафыннан 1,8 тапкырга арттырыла. Бу сумма йортта яшәүче, кайсы пенсионер, кайсы яртышар ел хезмәт хакы алмаган кешеләрнең кесәсенә каты суга. «Газ мәсьәләсендә эш анда яшәүчеләргә генә төртелеп калды. Акча түләнүгә газ җибәреләчәк»- ди С.Филлипов.

Ә менә җылытуга килгәндә хәл тагын да катлаулырак. «Сельхозтехника» АҖ котельнясыннан җылылык инде безгә мәгълүм йорт белән бергә тагын 34 йортка һәм «Колосок» балалар бакчасына җибәрелә. Ләкин ул җылылыкның өйне түгел, батареяларны җылытырга да җитмәве предприятиенең соңгы еллардагы аяныч финанс хәленә бәйле, аерым алганда, котельныйга ягулыкның җитәрлек дәрәҗәдән шактый түбән булуы нәкъ шуның белән аңлатыла.

Шунысын әйтергә кирәк, бу хәл быел тагын да кискенрәк төс алган: нечкәлекләргә үтеп кермичә (чөнки алар барыбер халыкны җылытмаячак) җитәкчелекнең җавабыннан аңлашылганча, биредә яшәүчеләргә өйдә кышкы киемнәрен салырга туры килмәячәк булырга охшый - кыскасы, ягулык юк, аны сатып алырга акча да юк. Кыш кына мәрхәмәтле була күрсен...

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## АКЦИЯЛӘР САТЫП АЛАБЫЗ

***«Татнефть» АҖсенең өстенлекле акцияләрен.***

**Үзегез белән паспорт һәм реестрдан выписка кәгазе булу шарт.**

Советская ур., 94 адресына («Родина» кинотеатры бинасы) мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 18 - 61.

## Октябрь территориаль шифаханә кассасына 1997 нче елның 9 аенда кергән һәм исраф ителгән акча средстволары турында отчет.

| Күрсәткечләр исемнәре | 1996 ел | 1997 ел |
|---|---|---|
| **Кертемнәр** | | |
| 1 Агымдагы периодта барлыгы керде: | 3096237,4 | 8139825,1 |
| 2.1 Страховой взнослар | 2365011,0 | 2859433,2 |
| 2.2 Вексельләр | 42000,0 | 172741,6 |
| 2.3 Үзара исәп - хисаплар | 146154,3 | 1515510,8 |
| 3 Бюджеттан эшләмәүче кешеләр өчен түләүләр | 0,0 | 3001697,9 |
| 4 ОМСка федераль фонд субвенцияләре | 252212,3 | 17742,3 |
| 5 Пенялар | 287690,0 | 468875,4 |
| 6. Штрафлар | 0,0 | 65312,7 |
| 7. Башка кертемнәр | 3169,8 | 38511,2 |
| **Чыгымнар** | | |
| 1. Агымдагы период чыгымнар - барлыгы | 3214735,9 | 8092540,2 |
| 2. ОМС программасын финанслау, шул исәптән: | 2529745,6 | 6440297,2 |
| база программасы | 2089904,3 | 5356331,5 |
| 2.1 Льготалы медикаментлар | 439841,3 | 572000,0 |
| 2.2 РБКга күчерелгән | 64074,8 | 741746,4 |
| 3 Территориаль шифаханә кассасын тоту өчен чыгымнар | 161059,1 | 222207,7 |
| 4 Гражданнарны РТ һәм РФ шәһәрләре дәвалау - профилактик учреждениеләрендә дәвалаган өчен түләү. | 20015,1 | 116288,9 |

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Кадерле өлкән хезмәттәшебез, остазыбыз **Разия Галиулла кызы Нуретдинованы** чын күңелебездән 70 еллык юбилее белән котлыйбыз. Аңа хөрмәтле Әни, кадерле әби булып, безнең ихтирамыбызны тоеп озак еллар сәламәт, бәхетле яшәвен телибез, район газетасында 4 дистә ел куйган фидакарь хезмәте, игелеге өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.*

***Изге теләкләр белән «Дуслык» газетасы редакциясе коллективы.***

Әхмәт авылында яшәүче кадерлебез **Йөземхан Солухан улы Әхмәтовка** ноябрьдә 60 яшь тула. Аны юбилее белән тәбриклибез, ныклы сәламәтлек, балаларыңның игелеген күреп, кайгы - хәсрәтсез, әни белән тигезлектә яшәвегезне телибез.



Гомер үтсен, әйдә, чәч агарсын,<br>
Ә йөрәккә кырау төшмәсен.<br>
Килер көннәреңдә тик тазалык<br>
һәм шатлыклар гына өстәлсен.

**Тормыш иптәше, кызлары, кияүләре, оныклары һәм туганнары.**

*Фома авылында яшәүче кадерле әниебез **Хәлимә Вәгыйзь кызы Мәхмүтовага** шушы көннәрдә 60 яшь тулды. Аны чын күңелебездән олы юбилее белән котлыйбыз.*

*Юбилееӊ белән котлап, әнкәй,<br>
без телибез сиңа иң элек<br>
Ныклы саулык, бәхет, озын гомер,<br>
Бөтен гаиләбезгә иминлек.<br>
Син булганга, әни, без бәхетле<br>
Синең белән якты көнебез.<br>
Безнең белән син дә бәхетле бул,<br>
Сәламәтлек сиңа телибез.*

***Тормыш иптәшең, балаларың исеменнән кызың Фәридә.***

## Белдерүләр


### САТАБЫЗ

**5 х 6 метрлы яңа чанадагы гараж.**
Адрес: К.Маркс ур., 1 - 19.

***

**1995 нче елның ноябрендә чыккан «Сафари» төсендәге ВАЗ 21099, инжектор экспорт варианты, «Сонни».** Тел.: 5 - 15 - 95 яки 65 - 0 - 53.

***

**Сыер.** Чуваш Мәнҗесе авылында Ильичов Юрийга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ике бүлмәле фатир сатыла яки Димитровград шәһәрендә шундый укка алыштырыла**. Тел.: 2 - 19 - 35, 17 сәг.тән соң.

***

**«Дружба» циркуляциясе, бензопычкы.**
Адрес: Югары Норлат авылы, Сираҗева Наҗия.

***

**Данәләп шомартылган каен паркет, 1 кв. метры 65 мең, сатуда 70 кв. метр бар**. Тел.: 5 - 26 - 68.

***

**1980 нче елгы ВАЗ - 2102**. Тел.: 2 - 35 - 34.

***

**«Москвич - 412», кыйммәт түгел**. Тел.: 2 - 24 - 99.

***

**Фундаменты белән участок. Көнчыгыш микрорайонында Нәҗипкә мөрәҗәгать итәргә**. Тел.: 3 - 32 - 46.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**6 ай яшәп тору өчен телефонлы, җиһазлы фатир кирәк. Түләү - ай саен.** Тел.: 2 - 22 - 97.

### «Наркодел»

**Алкогольгә бәйлелектән котылу өчен зыянсыз һәм нәтиҗәле чәй. Аноним кабул итү мөмкин. 24 нче ноябрьдә 11 сәгатьтән 13 сәг.кә кадәр район мәдәният йортында сатылачак.** Тел.: 5 - 16 - 55. Лицензия 000102, Мәскәү ФДСы тарафыннан 28. 09. 95 елда бирелгән.


«Агрохимсервис» АҖсе коллективы әнисе үлү сәбәпле **Сәйфетдинова Рәисә Гарифулла** кызының тирән кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР Р.Ф.ЖАМАЛИЕВ.
МӨХӘРРИР С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.